Вәлитова, З. Чаллы Сабан туе бит ул! /З. Вәлитова, А. Имамова. - Текст: турыдан-туры //Шәһри Чаллы. - 2022. - № 43 (22 июнь). - Б. 4.



# Чаллы Сабан туе бит ул!

Чаллыда Сабан туе гөрләп узды. Бәйрәм шәһәр халкын, кунакларны – олысын-кечесен бер мәйданга җыйды. Шәһәрдәшләребезне милли бәйрәм белән котларга ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, шәһәр мэры Наил Мәһдиев, ТР сәнәгать министры Олег Коробченко килде. Хөрмәтле кунакларны Чаллыда яшәүче төрле милләт вәкилләре җыр-биюләре белән каршы алды.



ФОТО: ШӘҺӘРНЕҢ РӘСМИ САЙТЫННАН АЛЫНДЫ

## Татар авылы йорты



ФОТО: ШӘҺӘРНЕҢ РӘСМИ САЙТЫННАН АЛЫНДЫ

Аннан соң кунаклар яңартылган «Авыл» мәйданчыгына уздылар. Анда төп йорт «XIX гасыр башындагы татар өе» рәвешендә башкарылган. «Авыл»да сандыклар, самоварлар, милли сувенирлар, кул эшләнмәләре күргәзмәсе оештырылган иде. Үз эшләнмәләрен Татарстанның төрле шәһәрләреннән, районнарыннан, күрше төбәкләрдән килгән халык осталары тәкъдим итте. Биредә курайлар, агачтан шкатулкалар, балчык савыт-сабалар, шәлләр, милли бизәкле кун сумкалар ясаучы осталар да үз эшләрен күрсәттеләр.

«Авыл»ның үз тегермәне, күле бар. Анда балалар балык тотып утыра. Наил Мәһдиевның «Балык эләгәме?» дигән соравына 5нче сыйныф укучысы Мансур Габидуллин «Әйе» дип җавап бирде. Малай 39нчы мәктәптә укый, «Эврика» мәдәният үзәгенә театр түгәрәгенә йөри.

Мәртәбәле кунакларны татар өендә мичтә пешкән коймак белән сыйладылар. Соңыннан аларны Сабан туе гүзәлләре каршы алып, төп мәйданга озаттылар.

## «Туган җирем – назлы бишегем!»

Бәйрәмнең төп мәйданында «Туган җирем – назлы бишегем!» дип аталган театраль тамаша тәкъдим ителде. Чарада мәктәп укучылары, студентлар, шәһәребезнең вокаль һәм хореографик ансамбльләре – барлыгы 1500дән артык кеше катнашты. Чаллыларны бәйрәм белән ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм шәһәр мэры Наил Мәһдиев котлады.

– Сабантуй бәйрәме быел искиткеч югары дәрәҗәдә оештырылган. Халык бәйрәмнәргә сусаган, ул аны ел буе көткән. Чаллы Сабантуе һәр елны үзенең масштабы белән аерылып тора – монда халык күп килә. Чаллылар республикабыз икътисадына, мәдәни тормышына һәм социаль үсешенә керткән өлеше белән горурлана ала, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Аннан соң төрле тармакларда эшләүче алдынгы хезмәткәрләргә дәүләт бүләкләре бирелде.

Ачылу тантанасыннан соң төп мәйданда ТРның халык артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге дәүләт фольклор ансамбленең концерт программасы күрсәтелде. Айдар Фәйзрахманов халык янына төшеп, кул биреп күреште. Халык ансамбль кызларына һәм егетләренә кушылып, рәхәтләнеп җырлады һәм биеде. Тамашачы аларга бик озак алкышлады. Шәһәрдәшебез Рузилә Фәхриевага да быелгы Сабантуй бик ошаган. «Иртән торып, озак кына уйлап яттым башта: Сабантуйга барыргамы, бакчагамы? Ярый әле бәйрәмне сайлаганмын. Шундый үзенчәлекле булды быел Сабантуй, башка еллардан нык аерыла. Ачылышы искиткеч матур, тирән мәгънәле, төрле темаларны үз эченә алган. Аеруча Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор ансамбль чыгышы ошады», – диде ул.




ЗӘҺРӘ ВАЛИТОВА ФОТОСЫ

## Уеннар

Чаллы Сабантуена килгән шәһәрдәшләребез һәм кунаклар уеннарда актив катнашты. Биредә өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә төрле бәйгеләр оештырылды: капчык белән сугышу, авыш баганага менү, кашыкка йомырка куеп, капчык киеп йөгерү һәм башкалар.

13 яшьлек Альфред Хисамов капчык белән сугышып, өч кешене җиңгән.

– Ел саен Сабантуйга килеп уеннарда катнашам. Капчык белән сугышуны бик яратам. Җиңдем. Мин бик шат. Әниемә кирәге чыгар – бүләккә табак алдым. Башка ярышларда да җиңдем, су пистолеты, сыбызгы, скакалка һәм башка бик күп бүләкләр оттым, – диде малай.

Роза Бәшәрова көянтә белән су ташуда көндәшен җиңде.

– Мин бит авыл баласы, көянтә белән күп йөрдек. Шуңа күрә җиңү авыр бирелмәде, – ди 70 яшьлек Роза апа.

Гөлия Сәхәпованың сумкасы бүләкләр белән тулган. Шулай да ул уеннарда катнашуын дәвам итә. Чираттагысы – бау белән машинаны тарту. Башта ир-атлар тартып карадылар, аннан – хатын-кызлар. Әйтергә кирәк, Гөлия дә ир-атлардан калышмады, машинаны тарта алды. Ир-атлар моны 7-8 секунд эчендә эшләсә, аңа 18 секунд вакыт кирәк булды.

– Бу уенда икенче ел катнашам. Ике тонналык машинаны тарту авыр түгел, бу миңа адреналин бирә, – диде ул.

Игезәкләр Александр белән Юрий Муравьевлар милли уеннарда катнашыр өчен Яшел Үзәннән махсус килгәннәр. Алар баганага менү буенча чемпионнар: 7 секунд эчендә менеп җиткән чаклары булган.

– Бу уенда 20 елдан артык катнашабыз. Республикабызның бик күп шәһәрләрендә булдык, гел призлы урыннар яулыйбыз. Былтыр Чаллыда 3нче урынны алдым, спорт кибетенә 6 мең сумлык сертификат оттым. Моннан тыш, тәкә, әтәч, бик күп көнкүреш техникасы оттык. Быел да көчебезне сынап карар өчен килдек, – диләр Александр белән Юрий.

Баганага менү жирәбә буенча башкарыла. Юрийның чираты – беренче. Ул әз генә менде дә кире төште.

– Багана бик шома, менеп булмый, – диде ул.

Илгизәр Сафинга 59 яшь. Ул 15 елдан артык баганага менә. Бүген дә җиңү яулар өчен килгән.

– Яшьләр белән ярышырга яратам. Чаллыда биш тапкыр җиңүче булдым. Телевизор, диван, микродулкынлы мич отканым булды. Бер елны спорт кибетенә сертификат бүләк иттеләр, шул акчага көймә алдым, күңелемне тынычландырдым, – ди ир-ат.

Бүген ул баганаың яртысына кадәр менде дә кире төште.

– Быел багана бик шома. Аяк-кулларымны махсус бал эремәсе белән сыласам да, менеп булмый, хәл бетә. Астагы өлешенең диаметры да киң, тотынып булмый, – диде Илгизәр абый.

Баганага менәргә теләүчеләр 30дан артык кеше иде, арасында хатын-кызлар да бар. Баганаың биеклеге 23 метр. Беркем дә менә алмас шикелле тоела, ул шундый биек. Тик шулай да утыз кеше арасыннан Рөстәм Хөсәенов багана башына менә алды.

– Мин тугыз ел бу уенда катнашам, гел икенче-өченче урыннар ала идем, соңгы өч елда менмәдем. Быел көчемне сынап карарга булдым. Баганага менү нык авыр, 5-6 метр менәсең дә хәлсезләнәсең, аска таба шуа башлыйсың, багана бик шома. Өскә менеп җитәргә 6 метр калгач, аңымны җуя башладым. Ләкин монда хәтле менеп җиткәч, бөтен көчемне җигеп, көчкә ахырына кадәр барып җиттем, – диде Рөстәм.

Рөстәм бер минут 30 секунд эчендә менде. Төшкәч, бик озак хәл җыеп утырды.

**Зөһрә Вәлитова**



ЗӘҺРӘ ВАЛИТОВА ФОТОСЫ

# Ат чабышлары – Сабан туе күрке

Быел ат чабышлары булачак урынга иртүк агылды халык. Старт биреләчәк минутларны тамашачылар белән бергә жайдаклар, ат хуҗалары һәм, әлбәттә, малкайлар ашкынып көтте.
– Балачактан бирле Сабантуйның иң яраткан мизгеле бу минем өчен. Шушы акыллы малкайлар чапканда минем дә йөрәгем урыныннан чыгардай булып тибә. Хайваннарны бик яратам, шуңа иртән үк килдем, – дип сөйләде миңа Гөлгенә Ибатуллина.
Старт бирелүгә, тамашачылар кул чаба, сызгыра, атларга көч бирә башлады. Әмма ярыш – ярыш инде: беренче әйләнештә үк кемдер алга ыргылды, кайсысы арткарак калды. Ә атларның барысына да бүләкләр әзерләнгән иде. Ат хуҗаларына акчалата бүләкне «Тулпар» ат-спорт мәктәбе директоры Вилсур Миннһаҗев тапшырды.
Ярышларга Татарстанның төрле төбәкләреннән, күрше Башкортстаннан барысы 125тән артык җайдак килгән иде. Атлар 1600, 2400, 3200 метр дистанцияләрдә чаптылар. Шәһәр мэры Наил Мәһдиев призына уздырылган ярышларда Дубай Шван исемле ат белән Азнакай районы егете Рамил Гайнанов беренче килде. ТР Дәүләт Советы депутаты Олег Николаев призына үткәрелгән ярышларда Башкортостанның Яркәй районы егете Рузил Мостафинга тиңнәр булмады. Тукай районы башлыгы Фаил Камаев призына уздырылган ат чабышларында шулай ук Башкортостан аты Том Форд беренче килде. Мөслим



ГӨЛИЯ ИБАТУЛЛИНА ФОТОСЫ

районының Лебенсон Гановер исемле аты «Сетевая компания» генераль директоры Илшат Фәрдиевнең махсус призына лаек булды.
Ярышлар вакытында Дакота Грейс исемле атның хуҗабикәсе Светлана Березина белән сөйләштем.
– Яратып «Котя» дип эндәшәм атыма. Махсус печән, чит илдән алып кайтылган мюсли ашатам. Моннан тыш, ваниль кушылган сохарилар сатып алабыз. Атымны тәмле ризыклар белән сыйлап кына торам. Алганыма ике ел. Төрле конкурсларда катнашабыз шулай. Күптән түгел Мәскәүгә ярышларга бардык. Анда 150гә якын ат бар иде. Призлы урын алмасак та, үзебезне күрсәтеп кайттык. Җайдак – Азалия Әхмәтнурова. Дакотада ул гына йөри. Алар бер-берсен күз карашыннан аңлыйлар, – дип сөйләде безгә Светлана ханым.
Ат чабышларында ишәкләр дә катнаштылар – Ипподромда ишәк ярышлары узды. 12 яшьлек Настя Куракина белән Ләйсән Габделгалиева «Тулпар» ат-спорт мәктәбендә шөгыльләнүләрен әйттеләр. Аларга бу ярышта ишәк өстеннән бер-берсен этеп төшерергә кирәк иде.
Бу ярышлар да искиткеч күңелле үтте.

# Милли көрәш – иң көтеп алынган мизгел

Көрәш ярышлары бик киеренке барды. Җанатарлар бик актив булды. Халыкны хәтта өстән коеп торган яңгыр да



ГӨЛИЯ ИБАТУЛЛИНА ФОТОСЫ



ЯШҮСМЕРЛӘР АРАСЫНДА АБСОЛЮТ БАТЫР АРТУР ХАЛИКОВ / ГӨЛИЯ ИБАТУЛЛИНА ФОТОСЫ

куркытмады.
70 килограмм авырлыктагы ир-атлар арасында чемпион булып Айназ Тимеров калды. 80 килограмм авырлыктагы ир-егетләрдән Ринат Шәйхетдиновка тиңнәр булмады. Яшүсмерләр *арасында* беренчелекне Артур Халиков яулады. Аңа 120 килограммлы тәкә тапшырылды.
Иң киеренке көрәш абсолют батырны билгеләгәндә булды. Финалда Эльдар Хәмитов («Копченый») белән Рәнис Гыйләҗетдинов («Гелик») очраштылар. Трибунада «Гели-и-и-к», «Гелик, давай!» дигән сүзләр ишетелде. Икенче баштан исә «Копченый, булдырасың!» дип кычкырдылар. Көрәш барган келәм янында ук йөреп, егетләрнең ни дәрәҗәдә әзерлекле, түзем, чыдам булуларын күзәттем. Меңә беренче балл Рәнис Гыйләҗетдиновка бирелде. Трибунада утырган халык шау-гөр килде. Рәнисне беренче балл алуы белән котладылар. «Копченый» Хәмитовка да көч биреп утыручылар күп булды.
– Хәзер инде беренче балы булган Рәнискә вакыт бик акрын барган төсле булачак. Ә Эльдар өчен вакыт, киресенчә, тиз үткән шикелле тоелыр. Алар өчен ярышларның минуты түгел, һәр секунды кадерле бит, – дип сөйләде хөкемдар.
**Көрәш осталарының берсенең дә бирешәсе килмәде.** Җитмәсә, яңгырдан соң *чыланган* келәм дә авырлыклар тудырды. Ничек итсә итте, бер ел элек үзенә «Җиңәм!» дип сүз биргән Рәнис беренчелеккә чыкты! 130 килограмм авырлыктагы абсолют батыр Рәнис Гыйләҗетдиновка шәһәр мэры Наил Мәһдиев «Лада Веста» машинасы ачкычы һәм 130 килограммлы тәкә бүләк итте. Чемпион тир һәм көч түгеп җиңеп *алган* машинага утырып мәйдан әйләнде. Күркәм традиция буенча, Сабан туеның абсолют батырын «Сабан туе гүзәле – 2022» бәйгесе җиңүчесе Эльвина Шәйхетдинова да котлады.
– Ел буе әзерләндем бу ярышларга. Бүген минем бик бәхетле көнем! Миңа бөтенесе ышанды, аеруча туганнарым, якыннарым гел янымда булды*лар*, теләктәшлек белдерделәр. Былтыр җиңүгә ирешә алмаган идем, бу миңа нииндидер этәргеч, стимул биреп торды. Әлеге җиңүем – минем ел буе әзерләнгән тырышлыгым! Көндәшем Эльдар да искиткеч көчле, тырыш егет. Аңа уңышлар телим, – дип сөйләде без*гә* чемпион.

**Гөлия Ибатуллина**



АБСОЛЮТ БАТЫР РӘНИС ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВ / ГӨЛИЯ ИБАТУЛЛИНА ФОТОСЫ

# Мәйдан сәхнәсендә – йолдызлар

Чаллы Сабан туеның кичке программасын шәһәребезнең танылган җырчылары башлап җибәрде. Алар мәйданны «кыздырган» арада халык урыннар алып калырга ашыкты. Яшьләр бию мәйданына җыелды, өлкәннәр эскә*мияләрне* үз итте. «Күңел» радиосы әзерләгән концерт башланганда мәйданда алма төшәрлек тә урын калмаган иде. Бер сәгать дәвамында сәхнәдә татар эстрадасының иң популяр җырчылары чыгыш ясады. Радионың алып баручылары Алинә Вәлиева һәм Ришат Хаҗиев аларны сәхнә түренә чакырып торды. Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар, Әлфинә Әзһәмова, Лилия Хәйруллина, Марат Яруллин, Илмира Нәгыймова, Филүс Каһиров, Гөлнара Тимерҗанова, Рәдиф Зарипов Чаллы Сабан туен котлап үзләренең популяр җырларын башкарды. Халык һәркайсын алкышлап каршы алды. Бу вакытта мәйданда чын бәйрәм рухы хөкем сөрде.
«Чаллы Сабан туенда беренче тапкыр чыгыш ясыйм. Бик дулкынланган идем, Чаллы колач җәеп каршы алды. Әнә никадәр кеше җыелган. Шәп Сабан туе бу!» – диде Татарстанның һәм Башкортостанның атказанган артисты Филүс Каһиров.
Лилия Хәйруллина өчен дә Чаллыда чыгыш ясау куанычлы. «Туган шәһәремә кайтып җырлау минем өчен шатлык. Монда минем балачагым узды. Чаллы һәрвакыттагыча дәртле, монда чыгыш ясау үзе бер рәхәт», – диде ул.
Гөлнара Тимерҗанова әле үз исеме белән чыгыш ясаса, киләчәктә аны башка исем белән таныячаклар. «Мин хәзер Гөлнара түгел, ә Наимә булам. Исемемне үзгәрттем. Ул җан тынычлыгы дигәнне аңлата. Киләчәктә яңа исемем белән чыгачакмын. Сабан туена килгәндә, иң зур теләгем – басуларда иген уңсын, илләр имин, күңелләребез тыныч булсын», – диде җырчы.
Салават һәм Гүзәлемнең яннарында кызлары Мәдинә дә бар. «Сабан туе котлы булсын! Һәркемгә матур җәйләр, күңелле яллар телибез», – дип теләкләрен җиткерде җырлы гаилә.
Кичке концертны танылган җырчы Илнур Гомәров алып барды. Шәһәрдә дәрәҗәле бәйрәмнәр аннан башка узмый. Сабан туенда «Эх, пятачоклары!» җыры да яңгырады. Күренеп тора, Чаллы әлеге җырны аеруча яратып тыңлый. Биергә урын да булса, шунда ук түгәрәк ясап әйләнер иде халык.



ГҮЗӘЛ УРАЗОВА / ФОТО МӘДӘНИЯТ ИДАРӘСЕННӘН

Сәгать тугызда бәйрәмнең төп кунаклары Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимов чыгышларын башлап җибәрде. Каршы алуларыннан ук күренеп тора, халык зарыгып көткән. Популяр җырларны кушылып та, яттан да җырладылар. «Сезне бөтен дөнья күрсен әле. “Чаллы, сез мондамы?” дигәч, нык итеп кычкырыгыз. Киттек!» – дип, җырчылар Чаллы халкын видеога да төшереп алды. Халык та үз чиратында җырчыларны шатландырды: телефоннарында фонарьларын кушып, мәйданда романтик мохит тудырды. Сабан туеның кульминациясе, гадәттәгечә, фейерверк. Быел Чаллы Сабан туе кунаклары аның тагын да матуррак булуын әйтте.

**Айзирә Имамова**



ГҮЗӘЛЕМ ҺӘМ САЛАВАТ МИҢНЕХАНОВЛАР / АЙЗИРӘ ИМАМОВА ФОТОСЫ